## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт авылы торак пунктында граждannар җыены нәтиҗәләре турында

**13.11.2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 14 ноябрендә 11.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан,ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Колмәт авылы территориясендәге чүп үләннәрен чабу һәм җыештыру (ягулык-майлау материаллары ,триммер)сатып алу;

2) Колмәт авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

3) Колмәт авылы тукталышына, тукталыш павильонын сатып алу һәм урнаштыру;

4) яңа юл билгеләре сатып алу һәм урнаштыру;

5) Колмәт авылында спорт ярышлары уздыру өчен призлар, бүләкләр сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 101 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 90 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 300 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Колмәт авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан ; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ

булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Колмәт авылы территориясендәге чүп үләннәрен чабу һәм җыештыру (ягулык-майлау материаллары ,триммер)сатып алу;

2) Колмәт авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

3) Колмәт авылы тукталышына, тукталыш павильонын сатып алу һәм урнаштыру;

4) яңа юл билгеләре сатып алу һәм урнаштыру;

5) Колмәт авылында спорт ярышлары уздыру өчен призлар, бүләкләр сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче — И.Н.Хадиуллин